**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАПШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422708, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Шапши, ул. Ленина, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘПШИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422708, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Шәпши авылы, Ленин ур., 1

тел./факс 8(84365) 77-2-36, e-mail: Shap.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 30.09.2020 г.** **№6**

**Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлегенең бухгалтерлар хезмәте өчен түләүне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 05 августындагы 655 нче номерлы «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» карары нигезендә Биектау муниципаль районының Шәпши авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 октябреннән бухгалтерларның айлык вазыйфаи окладлары күләмен (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) 1,03 тапкырга арттырырга.

2. Шәпши авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 6 декабрендәге 15 нче номерлы «Баш бухгалтерлар һәм бухгалтерларның, Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендә аерым оешмалар хезмәткәрләренең, Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлеге Башкарма комитетының хәрби-исәпкә алу хезмәткәрләре хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» карары белән расланган «Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлегенең бухгалтерлар хезмәте өчен түләүне (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) оештыру һәм шартлары турында» Нигезләмәнең 3 пунктына «Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлегенең бухгалтерларның вазыйфаи окладлары» таблицасына түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары халык саны белән | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән артыграк |
| Баш бухгалтер | 16171 | 17510 |
| Бухгалтер | | 14935 |

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Шәпши авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Беляков